**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2708**
**27.05.2019**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтелә торган муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсе 6 бүлегенең 3 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр һәм федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлар органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек турында» 2011 елның 27 сентябрендәге 797 нчы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтелә торган муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2019 елның 27 маендагы
2708 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтелә торган муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеге

| | |
|---|---|
| 1. | «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү. |
| 2. | Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую. |
| 3. | Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую. |
| 4. | Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны исәпкә кую һәм Дәүләт торак сертификаты бирү. |
| 5. | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү. |
| 6. | Күп фатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру эшләрен килешенү. |
| 7. | Торак бүлмәләрне гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү. |
| 8. | Социаль наем килешүе буенча гражданга муниципаль милектәге торак бүлмәне бирү. |
| 9. | Социаль наем килешүе буенча бирелгән торак бүлмәләрне алмаштыру буенча документлар рәсмиләштерү. |
| 10. | Бүлмәне торак бүлмә, торак бүлмәне яшәү өчен яраксыз, күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки яңартып төзелергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану. |
| 11. | Торак бүлмәне торак булмаган бүлмә һәм торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерү. |
| 12. | Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү. |

| | |
|---|---|
| 13. | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү. |
| 14. | Кадастр исәбенә кую максатында муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир участокларының чикләрен килешенү. |
| 15. | Реклама корылмасын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү. |
| 16. | Җир участокларының шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү. |
| 17. | Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару |
| 18. | Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү. |
| 19. | Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яки утыртуга рөхсәт бирү. |
| 20. | Җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юллары торышы турында мәгълүмат бирү. |
| 21. | Муниципаль мөлкәтне оператив идарә хокукында муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә һәм хуҗалык алып бару хокукында муниципаль унитар предприятиеләргә рәсмиләштерү (беркетү). |
| 22. | Муниципаль милектәге җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү. |
| 23. | Территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасын раслау. |
| 24. | Муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү. |
| 25. | Муниципаль милектәге җир участогын җир участогында урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү |
| 26. | Җир участогыннан даими (сроксыз) файдалану хокукын яки җир участогын гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү. |
| 27. | Муниципаль милектәге җир участогын түләүсез файдалануга бирү. |
| 28. | Муниципаль милектәге җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү |
| 29. | Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату. |
| 30. | Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү. |
| 31. | Җир участогын арендалау килешүенә үзгәрешләр кертү. |
| 32. | Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү. |
| 33. | Архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләрен бирү. |

| | |
|---|---|
| 34. | Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир участокларын милеккә бушлай бирү (тапшыру). |
| 35. | Муниципаль казна мөлкәтен арендага бирү |
| 36. | Чит җир участогыннан чикле файдалану хокукы (сервитут) бирү. |
| 37. | Элек приватизацияләнгән торак бүлмәләрне муниципаль милеккә кабул итү. |
| 38. | Җир участогының шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү. |
| 39. | Коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып торган гражданга җир участогын бушлай бирү. |
| 40. | Хезмәт урыныннан бирелә торган торак бүлмәне наемга алу килешүе буенча гражданнарга торак бүлмәләр бирү. |
| 41. | Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасы мәгълүматларын бирү. |
| 42. | Җир участогын арендалауның гамәлдәге килешүен өзү. |
| 43. | Җир участогын субарендага тапшыруга рөхсәт бирү. |
| 44. | Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге килешүен өзү. |
| 45. | Муниципаль берәмлекнең муниципаль мөлкәтен сатулар үткәрмичә түләүсез файдалануга тапшыру. |
| 46. | Муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе төзү хокукына сатуларның нәтиҗәләре буенча шундый килешү төзү. |
| 47. | Муниципаль преференцияләр бирү. |
| 48. | Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү. |
| 49. | Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирү. |
| 50. | Җир участогы бирүне алдан килешенү. |
| 51. | Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү. |
| 52. | Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын һәм шәхси милектәге җир участокларын яңадан бүлү турында килешенү төзү. |
| 53. | Муниципаль милектәге җир участогын бакчачылык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү. |
| 54. | Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү. |
| 55. | Җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда сату юлы белән муниципаль милектәге җир участогын милеккә бирү. |
| 56. | Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспорт) килешенү. |

| | |
|---|---|
| 57. | Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне яисә җир участокларын файдалануга рөхсәт бирү. |
| 58. | Яр Чаллы шәһәре өстендә авиация эшләре, парашюттан сикерү, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз очу аппаратларының очышлары, бәйләп куела торган аэростатларны күтәрү, шулай ук алар хакында белешмәләр аэронавигация мәгълүматлары документларында күрсәтелмәгән Яр Чаллы шәһәре чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга төшү (очып китү) өчен рөхсәт бирү. |
| 59. | Муниципаль белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын, шулай ук өстәмә гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру турында мәгълүмат бирү. |
| 60. | Планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү (рөхсәт ителмәү) турында белдерү кәгазе җибәрү. |
| 61. | Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү. |
| 62. | Җир участогының рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү. |
| 63. | Социаль файдаланудагы торак фондының торак бүлмәләрен наемга алу килешүләре буенча торак бүлмәләр бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу. |
| 64. | Чит җир участогыннан чикле файдалану хокукы (җәмәгать сервитуты) бирү. |
| 65. | Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү. |
| 66. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килешенү. |
| 67. | Каты коммуналь калдыкларны җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү. |

| | |
|---|---|
| 68. | Балигъ булмаганнарның күчемле милкен тартып алу буенча килешүләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү. |
| 69. | Ундүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү. |
| 70. | Балигъ булмаган затны эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча хокукка сәләтле дип белдерү) турында карар кабул итү. |
| 71. | Законлы вәкилгә балигъ булмаган затның акчалата кертемен алуга рөхсәт бирү. |
| 72. | Дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләрен бирү. |
| 73. | Аерылышуны дәүләт теркәвенә алу. |
| 74. | Язылышуны дәүләт теркәвенә алу. |
| 75. | Гражданнар хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклыклар бирү. |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова